БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» 03 2021 ел № 130

«Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең актуальләштерелгән административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 19 июлендәге 262 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына (2020 елның 18 ноябрендәге 321 номерлы, 2021 елның 5 мартындагы 108 номерлы үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәүнең көтелгән нәтиҗәләре һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең уртак коллегиясенең 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы Беркетмәсенең 24 пунктын үтәү йөзеннән, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210 – ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 22 гыйнварындагы 02-08-02-21 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең актуальләштерелгән административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 19 июлендәге 262 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары (2020 елның 18 ноябрендәге 321 номерлы, 2021 елның 5 мартындагы

108 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (1 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча өстәргә:

«8) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына - Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенә салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә.».

1.2. 3.4.1 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) индивидуаль эшкуар булган затның керемнәре турында 3-НДФЛ формасы буенча белешмәләр;»;

1.3. 3.4.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 8 пунктчасын өстәргә:

«8) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булуы (булмавы) турында белешмә.».

2. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең актуальләштерелгән административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 19 июлендәге 262 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары (2020 елның 18 ноябрендәге 321 номерлы, 2021 елның 5 мартындагы 108 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт кәгазе) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (16 нчы кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 Документлар исемлегенә түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына - Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенә салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар турында белешмә.»;

2.2. 2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктчасын өстәргә:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булуы.».

2.3. 3.4.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3 пунктчасын өстәргә:

«8) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар булуы (булмавы) турында белешмә.».

3. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең актуальләштерелгән административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 19 июлендәге 262 номерлы

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары (2020 елның 18 ноябрендәге 321 номерлы, 2021 елның 5 мартындагы 108 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (11 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1. 2.6.пунктының 5 пунктчасына «, шулай ук гарантияләүче электр энергиясе белән тәэмин итүчеләр вәкилләре тарафыннан имзаланган, күпфатирлы йортларның һәм күпфатирлы йортларда урыннарның электр энергиясен исәпкә алу приборларын гарантияләүче электр энергиясе белән тәэмин итүчеләргә файдалануга тапшыруны раслаучы документлар» сүзләрен өстәргә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов